КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 декабрь г.Казань № 1216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 1 март, 148 нче; 2019 ел, 24 апрель, 339 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче һәм 2019 ел, 28 август, 711 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның өченче абзацында «бөлгенлек» сүзен «аңа карата бөлгенлек процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның алтынчы абзацында «10,0» саннарын «10,0» саннарына алыштырырга;

8 нче пунктның өченче абзацында «бөлгенлек» сүзен «аңа карата бөлгенлек процедурасы кертелмәве, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы» сүзләренә алыштырырга;

12 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Идарәләр, кирәк булганда, алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

13 нче пунктта:

«а» пунктчасында «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләре» сүзенә алыштырырга;

«б» пунктчасында «субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен – «субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап» сүзләренә, «субсидия алучы» сүзләрен «алучы» сүзенә алыштырырга;

бу Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле яңа $13^1$ һәм $13^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$13^1$. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – субсидия бирелә торган елда бөртекле, кузаклы, азык культуралары мәйданнарын яки барлык чәчү мәйданнарын планлаштырылган мәйданнарга карата саклап калу.

$13^2$. Субсидияләр алучылар Идарәләргә субсидияләрне алган елдан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән формада субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплар кертә.»;

бу Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. 2019 елда ачык грунтта яшелчәләр җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен алучыларга бирелә торган субсидия күләмен билгеләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибе нигезендә (бу карарның 1 нче пункты белән кертелгән үзгәрешләр

редакциясендә) алар тарафыннан 2019 елда шул ук максатлар өчен әлеге Тәртип нигезендә алынган субсидияләр исәпкә алына, дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, шулай ук фәнни оешмаларга, һөнәри белем бирү оешмаларына, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның ___________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

Алучының исеме: _________________________________
Дәвамлылыгы: елга бер тапкыр.

| Т/с | Күрсәткеч исеме | ГРҮБК буенча үлчәү берәмлеге* | | Күрсәткечнең план буенча әһәмияте | Хисап датасы хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | |
| 1. | Субсидия бирелә торган елда бөртекле, кузаклы, азык культуралары мәйданнарын яки барлык чәчү мәйданнарын планлаштырылган мәйданнарга карата саклап калу | гектар | 059 | | |

*ГРҮБК – Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы.

Алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ________________ ___________ _______________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Үтәүче ___________________________ _________________________________
(вазыйфасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

____________
(телефоны) 20__ ел, «__» ___________

____________________________